**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**23.04.2024** **№ 228**

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» Нурлат муниципаль районы Советының 2023 елның 09 августындагы 183 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2023 елның 09 августындагы 183 номерлы карары белән (Нурлат муниципаль районы Советының 2023 елның 22 ноябрендәге 210 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән) расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырылганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары» нигезләмәсенә 1нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (1нче кушымта) .

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе

Д.А. Ишкинеев

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2024 елның 23 апрелендәге 228 номерлы карарына 1нче кушымта

(Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә 1нче кушымта)

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен башкарганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары**

1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Россия Федерациясе Торак Кодексының 165 статьясының 5 өлеше нигезендә билгеләнгән тәртипкә, формаларга, срокларга һәм вакытлычалыкка ярашлы рәвештә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматның өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында актуальләшмәве.

3. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырыла.

4. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.